КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 декабрь г.Казань № 1179

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында китерелгән зыянны компенсацияләү максатларында 2019 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында китерелгән зыянны компенсацияләү өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 22 декабрендәге 1441 номерлы карары нигезендә, табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында зыян күргән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында китерелгән зыянны компенсацияләү максатларында 2019 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 20 декабрь, 1179 нчы
карары белән расланды

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында китерелгән зыянны компенсацияләү максатларында 2019 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында китерелгән зыянны компенсацияләү максатларында 2019 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – алучылар, субсидияләр) бирү механизмын һәм шартларын билгели.

2. Алучыларга табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында китерелгән зыянны компенсацияләүне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар субсидияләр бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып тора.

3. Субсидия бирү бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Субсидияләр Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның язгы чорында «Куркыныч метеорологик күренешләр комплексы» гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән төбәкләр тарафыннан тапшырылган үсемлекчелек объектлары һәлак булу буенча материаллар анализы турындагы 2019 елның 26 июнендәге 006с/1 номерлы актының кушымтасы булган 2019 елның язгы чорында «Куркыныч метеорологик күренешләр комплексы» гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән Татарстан Республикасының иминиятләштерелгән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре реестрына теркәлгән алучыларга бирелә.

5. Субсидия, алучы субсидия бирү турындагы карар кабул ителә торган көнгә кадәр 15 эш көненнән дә артмаган көнгә түбәндәге таләпләргә туры килгән очракта, бирелә:

законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм җитештерү эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырган;

бетерү процессында булмаган, аңа карата банкротлык процедурасы башланмаган, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан

артып киткән россия юридик заты булмаган;

бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмаган.

6. Субсидияләр анализ актына кушымта итеп теркәлгән 2019 елның язгы чорында «Куркыныч агрометеорологик күренешләр комплексы» гадәттән тыш хәлләрдән зыян күргән Татарстан Республикасының иминиятләштерелгән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре реестрында күрсәтелгән күләмдә алучыга бирелә.

Субсидия күләме Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең табигый характердагы гадәттән тыш хәлләрдән күргән зыянын бәяләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2015 елның 26 мартындагы 113 номерлы боерыгы нигезендә исәпләп чыгарыла.

7. Бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен алучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлыкның боерыгы белән расланган форма буенча үзенең түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән алучы турында түбәндәге мәгълүматлар бирелгән субсидияләр бирү турында гариза

законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлү һәм җитештерү эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру;

бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы башланмау, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмау;

алучы чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булмау;

бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар,

штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия күләме турында белешмә кәгазен.

Субсидия алучылар үз инициативасы белән салым органының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлары булмавын раслый торган белешмә кәгазен кертергә хокуклы. Әлеге документ субсидия алучы тарафыннан үз инициативасы белән кертелмәгән очракта, Министрлык аны салым органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

8. Министрлык:

субсидия алу турындагы гаризаны «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында кергән көнне теркәүгә ала;

гариза теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә:

тапшырылган документларның бу Тәртипнең 7 нче пунктына туры килү-килмәвен карап тикшерә;

субсидия күләме турындагы белешмә кәгазьләренең анализ актына кушымта итеп бирелгән 2019 елның язгы чорында «Куркыныч агрометеорологик күренешләр комплексы» гадәттән тыш хәлдән зыян күргән Татарстан Республикасының иминиятләштерелгән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрнең реестрына туры килү-килмәвен тикшерә һәм субсидия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

документларны тулы комплектта тапшырмау яки алар бу Тәртипнең таләпләренә туры килмәү;

алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүмат дөрес булмау.

Субсидия бирүдән баш тартылган очракта, Министрлык алучыга бу пунктның өченче абзацында күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә алучыга бу турыда хәбәрнамә җибәрә.

9. Министрлык Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып тора һәм субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә үзенең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси счетыннан алучыларның Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына субсидия күчерүне гамәлгә ашыра.

Анализ актының кушымтасы булган 2019 елның язгы чорында «Куркыныч агрометеорологик күренешләр комплексы» гадәттән тыш хәлләрдән зыян күргән Татарстан Республикасының иминиятләштерелгән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре реестры нигезендә төзелгән субсидия күләме турындагы белешмә кәгазе субсидия күчерү өчен нигез булып тора.

10. Алучыга анализ актына кушымта итеп бирелгән 2019 елның язгы чорында «Куркыныч агрометеорологик күренешләр комплексы» гадәттән тыш хәлләрдән зыян күргән Татарстан Республикасының иминиятләштерелгән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре реестрында билгеләнгән күләмдә зыянны компенсацияләү субсидия бирүнең нәтиҗәсе булып тора.

11. Субсидияләр алучылар субсидияләр алган елдан соң килүче елның 1 февраленә кадәр бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап кертә.

12. Бирелгән субсидияләр, Министрлык һәм вәкаләтле дәүләт финанс тикшерүе органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча бу Тәртип белән билгеләнгән субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын бозу фактлары ачыкланган очракта, шулай ук субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешмәгән очракта, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә бюджет законнары нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

13. Субсидия алучы бу Тәртипнең 12 нче пунктында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемена ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, Министрлык субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә әлеге субсидияләрне Татарстан Республикасы бюджетына закон белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

14. Законнар нигезендә Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

15. Субсидия алучылар тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык тиешле вазыйфаи затларга һәм җитәкчеләргә йөкләнә.

16. Бюджет акчасыннан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында китерелгән зыянны компенсацияләү максатларында 2019 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

20__ елның ________________ хәленә карата
субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
ХИСАП

Субсидия алучы исеме: __________________________________________

| Т/с | Нәтиҗә исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап көне хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе |
|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | |
| 1. | Субсидия алучыга зыянны 2019 елның язгы чорында «Куркыныч метеорологик күренешләр комплексы» гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән төбәкләр тарафыннан тапшырылган үсемлекчелек объектлары һәлак булу буенча материаллар анализы актының кушымтасы булган 2019 елның язгы чорында «Куркыныч метеорологик күренешләр комплексы» гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән Татарстан Республикасының иминиятләштерелгән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре реестрында билгеләнгән күләмдә компенсацияләү | сум | 383 | | |

Субсидия алучының
Җитәкчесе _______________ _____________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис.)

Баш бухгалтер _______________ _____________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис.)

20__ елның «____» _____________
Мөһере (булганда)

_________________________